КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1738

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 423 нче; 2022 ел, 29 март, 282 нче, 2023 ел, 20 гыйнвар, 25 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр шәһәр яны юлларында пассажирлар ташуга тарифларны дәүләт җайга салуына бәйле рәвештә, шулай ук гражданнарның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган аерым категорияләренә, гомуми белем бирү учреждениеләренең 7 яшьтән өлкәнрәк укучыларына һәм тәрбияләнүчеләренә, башлангыч һөнәр, урта һөнәр һәм югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләренең көндезге формада белем алучы укучыларына шәһәр яны элемтәсендә гомуми файдаланудагы тимер юл транс-порты белән хезмәтләр күрсәткәндә тарифлар буенча ташламалар бирү турында» 2013 ел, 4 март, 145 нче карарында күрсәтелгән аерым категорияләренә керү өчен түләүгә ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплау максатларында,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында бирелә.»;

9 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентган арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органы биргән белешмә кәгазе (мондый документ оешма тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешманың чит ил юридик заты, шул исәптән офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентган арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, оешманың җитәкчесе һәм ошаманың баш бухгалтеры тарафыннан кул куелган һәм мөһер белән таныкланган (булганда) белешмә кәгазе;

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр шәһәр яны юлларында пассажирларны ташуга тарифларны дәүләт җайга салуына бәйле, шулай ук гражданнарның Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны су транспортында хезмәт күрсәткәндә гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарында күрсәтелгән аерым категорияләренә керү өчен түләүгә ташламалар бирүгә бәйле рәвештә рәвештә алынмаган керемнәрне каплау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында бирелә.»;

9 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Оешма сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән срокта Министрлыкка Министрлык тарафыннан расланган форма буенча заявка бирә, ул шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турында, оешма биргән заявка турында мәгълүматны, оешма турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) рөхсәтне һәм түбәндәге документларны үз эченә ала:

эчке су транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе (күрсәтелгән документ оешма тарафыннан тәкъдим ителмәгән очракта, Министрлык аны Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә яисә аның территориаль органнарында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала);

пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле пассажир судноларының Россия Федерациясе законнары нигезендә милек хокукында яисә башка хокукта булуын раслый торган документларның күчермәләре;

Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча

йөкләмәләр салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертеме түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәлү турында салым органы биргән белешмә кәгазе (мондый документ оешма тарафыннан тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

оешма җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм оешманың Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычының һәм Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча кичектергесез (җайга салынмаган) башка бурычларының булмавын раслый торган оешманың мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмәсен;

оешманың җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән теркәлгән оешманың үзгәртеп кору процессында булмавын (башка юридик затны оешмага тоташтыру формасында үзгәртеп корудан тыш), ликвидацияләнүен, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслаган белешмә;

оешманың чит ил юридик заты, шул исәптән офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, оешманың җитәкчесе һәм ошаманың баш бухгалтеры тарафыннан кул куелган һәм мөһер белән таныкланган (булганда) белешмә кәгазе;

оешманың Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алмавын раслый торган, оешманың җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә оешма турында Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан алынган белешмәләр, сайлап алуда катнашуга гариза бирелгәнче бер айдан да соңга калмыйча (күрсәтелгән документ оешма тарафыннан тәкъдим ителмәгән очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә салым органында соратып ала).

Тапшырылган документларның күчермәләре оешма тарафыннан таныкланырга тиеш.

Оешма тәкъдим ителгән заявкаларда һәм документларда булган мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин